**Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Төги авыл җирлеге составына керүче Алексеевка торак пунктында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында**

**КАРАРЫ**

**12.11.2025** **№ 2**

«Гавами хакимиятнең бердәм системасында җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2025 елның 20 мартындагы 33-ФЗ номерлы Федераль законның 45, 69 статьялары нигезендә, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә №45-ТРЗ «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында», Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районының Төги авыл җирлеге Уставына таянып 2025 елның 12 ноябрендә «Сез 2026 елда Төги авыл җирлегенең Алексеевка торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 600 (алты йөз) сум күләмендә үзара салым акчаларын кертүгә, көндезге формада белем алучы студентлардан, 1 төркем инвалидлардан, ялгыз картайган гражданнардан, Россия Федерациясе Кораллы Көчләрендә мобилизация буенча хәрби хезмәткә чакырылган гражданнардан тыш, һәм алдагы эшләрне башкару буенча җирле әһәмияткә ия мәсьәләләрне хәл итүгә алынган акчаларны җибәрүгә килешәсезме:

- торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмияткә ия булган автомобиль юлларын төзекләндерү, ремонтлау, карап тоту (зиратка кадәр юлны төзекләндерергә).».

Гражданнар җыены нәтиҗәләре турындагы беркетмә нигезендә:

Җыенда катнашучылар исемлегенә сайлау хокукы булган 77 кеше кертелгән, 70 кеше тавыш бирүдә катнашкан гражданнар җыенында катнашучылар саны.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенында катнашучылар тавышы түбәндәгечә бүленде:

«ӘЙЕ» позициясе өчен 68 кеше бирде;
җыенның 2 катнашучысы «ЮК» позициясе өчен тавыш бирде.

Бәян ителгәннәрдән чыгып, гражданнар җыены карар итте:

1. Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Төги авыл җирлегенең Алексеевка торак пунктында гражданнар җыены үткән, гражданнар җыенының нәтиҗәләрен дөрес дип тану.

2. «2026 елда Төги авыл җирлегенең Алексеевка торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 600 (биш йөз) сум күләмендә үзара салым акчаларын кертүгә, көндезге

формада белем  алучы студентлардан, 1 төркем инвалидлардан, ялгыз картайган гражданнардан, Россия Федерациясе Кораллы Көчләрендә мобилизация буенча хәрби хезмәткә чакырылган гражданнардан тыш алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияткә ия мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтү:

- торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмияткә ия булган автомобиль юлларын төзекләндерү, ремонтлау, карап тоту (зиратка кадәр юлны төзекләндерергә).»,

соравы буенча карарны кабул ителгән дип танырга.

3. Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районының Төги авыл җирлегенең Алексеевка торак пунктының мәгълүмат стендларына урнаштыру юлы белән гражданнар җыены нәтиҗәләрен игълан итәргә. Зәй муниципаль районының рәсми сайтында «Авыл җирлекләре» бүлегендә бастырып чыгарырга. «Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматының рәсми порталында» урнаштырырга (PRAVO.TATARSTAN.RU) 7 көн дәвамында (Төги авыл җирлеге Уставының 69 п.5 статьясы) кабул ителгән көннән.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районының Төги авыл җирлеге башлыгына җибәрергә.

**Гражданнар җыенында рәислек итүче,**
**Зәй муниципаль районы**
**Төги авыл җирлеге башлыгы** **Т.В. Попова**